РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 ноябрь , 2024 ел № 28

Кукмара поселок Советының 2009 елның 01 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган муниципаль милек объектларын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү турында концессия килешүләре төзү тәртибе хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 296-ФЗ номерлы Федераль закон, Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

Кукмара поселок Советының 2009 елның 01 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган муниципаль милек объектларын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү турында концессия килешүләре төзү тәртибе хакындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.9 пунктының 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8) концессия түләве күләме, аны кертү рәвеше яисә рәвешләре, тәртибе һәм вакыты – концессия килешүендә концессия түләве каралган очракта;»

1.2. Нигезләмәнең 3.10 пунктындагы 10 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев